КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 май г.Казань № 396

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына бирелгән хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендәге Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2013 ел, 13 сентябрь, 655 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына бирелгән хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендәге, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында»;

преамбулада «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» сүзләрен «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау

чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» сүзләренә алыштырырга;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына бирелгән хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендәге, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын (карарга теркәлә) расларга.»;

әлеге карар белән расланган Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына бирелгән хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендәге Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне теркәү тәртибен һәм этләрнең потенциаль куркыныч токымнары исемлеген раслау турында» 2014 ел, 5 май, 298 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 629 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында»;

преамбулада «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында этләрне теркәү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибе»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү

характерында (ирекле) теркәү (алга таба – этләрне теркәү) чараларын гамәлгә ашыру процедурасын билгели.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тәртип нигезендә эт хуҗасы төшенчәсе эткә милек хокукында яки башка законнар нигезендә ия булган физик зат яки юридик зат дигәнне аңлата.»;

4 нче пунктта:

өченче абзацта «хуҗаларына» сүзен «эт хуҗасына» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хуҗалары булмаган этләр булу проблемасын хәл итү;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Этләрне теркәү эт хуҗасы яшәгән урын яки булган урында этләрне теркәүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына (алга таба – Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган) яки аның ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария оешмасына (алга таба – ведомство буйсынуындагы оешма) гариза тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

6 нчы пунктта «хәбәр итү характерында» сүзләреннән соң «(ирекле)» сүзен өстәргә;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Этне теркәү өчен эт хуҗасы Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле органга яки ведомство буйсынуындагы оешмага этен тикшертү өчен алып килә, шулай ук Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган акты белән расланган форма буенча этне теркәү турында гариза тапшыра.»;

11 нче пунктның тугызынчы абзацында татар текстында «хуҗа» сүзен «эт хуҗасы» сүзләренә алыштырырга;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Этне теркәүне Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган яки ведомство буйсынуындагы оешма хезмәткәре эт хуҗасы мөрәҗәгать иткән көндә эткә тәңгәлләштерү санын бирү юлы белән үткәрә.»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Теркәүне рәсмиләштергәндә эт хуҗасына бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча этне теркәү турында таныклык бирелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) этнең теркәлгәндә бирелә торган тәңгәлләштерү саны;

2) эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), паспорт мәгълүматлары, аны булган урыны яки яшәгән урыны буенча теркәү турындагы, шулай ук фактта яшәгән урыны хакындагы мәгълүматлар (әгәр дә эт хуҗасы физик зат булса);

3) юридик затның исеме һәм булган урыны (әгәр дә эт хуҗасы юридик зат булса);

4) этнең токымы, җенесе, төсе, кушаматы, аерым билгеләре, этнең электрон мәгълүмат чыганагы (микрочип) булу турында мәгълүматлар;

5) эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактика ветеринария чаралары турында мәгълүмат;

6) эт асралачак урынның яки җир кишәрлегенең адресы.»;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Этне теркәү турындагы таныклык дубликатын алу өчен эт хуҗасы Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган акты белән расланган форма буенча этне теркәү турындагы таныклык дубликатын (алга таба – дубликат) бирү хакында гариза белән этне теркәү турында таныклык биргән Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле органга яки ведомство буйсынуындагы оешмага мөрәҗәгать итә.»;

17 нче пунктның икенче абзацында татар текстында «хуҗаның» сүзен «эт хуҗасының» сүзләренә алыштырырга;

18 нче пунктта «яки аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесе» сүзләрен «ведомство буйсынуындагы оешма» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктта «бу» сүзен төшереп калдырырга;

20 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Этне теркәү турындагы таныклыкны алыштыруны гамәлгә ашыру өчен эт хуҗасы Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган акты белән расланган форма буенча этне теркәү турындагы таныклыкны алыштыру хакында гариза белән этне теркәү турында таныклык биргән Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле органга яки ведомство буйсынуындагы оешмага мөрәҗәгать итә.

Этнең хуҗасы алмашкан очракта, әлеге гариза белән этнең яңа хуҗасы мөрәҗәгать итә.»;

21 нче пунктның икенче абзацында татар текстында «хуҗаның» сүзен «эт хуҗасының» сүзләренә алыштырырга;

23 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Этне теркәү исәбеннән төшерү эт үлгән яки ул күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшырылган очракта эт хуҗасы гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.»;

24 нче пунктта «аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесенә» сүзләрен «ведомство буйсынуындагы оешмага» сүзләренә алыштырырга;

25 нче пунктның икенче абзацы татар текстында үзгәрешсез кала;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада «Фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләрен «Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)» сүзләренә алыштырырга, «аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесе» сүзләрен «аның ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария оешмасы» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 13 сентябрь, 655 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 16 май, 396 нчы
карары редакциясендә)

Форма

Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына бирелгән хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендәге, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында

хисап

| Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Саны, данә | | Мәйданы, кв.метр | | Конструкцияләргә дезинфекция үткәрелде, кв.метр | | | | Территорияләргә хезмәт күрсәтү | | | Төзекләндерелде, данә | | Хайваннарның күпләп үлүе, баш | | | | Хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар | | | | | | | | | | | | | | Җирле үзидарә органына акча бирелде, мең сум | Җирле үзидарә органы тарафыннан чыгымнар тотылды – барлыгы, мең сум | | | Хисап чоры ахырына файдаланылмый калган акча, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | биотермик чокырлар | түләмәдән үлгән хайваннарның үләт базлары | биотермик чокырлар | түләмәдән үлгән хайваннарның үләт базлары | барлыгы | шул исәптән киртәгә | ачып | өслеккә | биотермик чокыр конструкцияләренә агымдагы ремонт, кв.метр | түләмәдән үлгән хайваннарның үләт базлары конструкцияләренә агымдагы ремонт, кв.метр | биотермик чокырны консервацияләү, данә | биотермик чокырлар | түләмәдән үлгән хайваннарның үләт базлары | сыерлар | дуңгызлар | сарыклар, кәҗәләр | атлар | хуҗасыз йорт хайваннары тотылды – барлыгы, баш | хуҗасыз йорт хайваннары транспорт белән йөртелде, баш | | хуҗасыз йорт хайваннарына карата дәвалау-профилактика чаралары үткәрелде, баш | | | | хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен приютта тоту, баш | | | | хуҗасыз йорт хайваннарына стерилизация ясалды, баш | хуҗасыз йорт хайваннарына кастрация ясалды, баш | дәвалап булмый торган авыр чирләре яки хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итү һәм хуҗасыз йорт хайваннары үләксәләрен утильләштерү – барлыгы, баш | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | хайваннар өчен приютларга | сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз йорт хайваннары үзләренең элек яшәгән урыннарына кире кайтарылды | барлыгы | вакцинация | дегельминтизация | дезинсекция | барлыгы | хуҗасыз йорт хайваннарының йогышлы авыруларын ачыклау өчен аларны мәҗбүри карантинга ябу | хуҗасыз йорт хайваннарын операциядән соң тоту | башка хайваннарга яки кешегә карата сәбәпсез агрессивлык күрсәтә торган һәм табигый рәвештә үлгәнгә кадәр хайваннар өчен приютта тотуга калдырылган | | | | | түләмәдән үлгән хайваннарның үләт базларын тотуга һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрүгә | биотермик чокырларны тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм биотермик чокырларны консервацияләү буенча чаралар күрүгә | хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чараларга | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 | 32 | 33 | 34 | 35 | 36 | 37 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җирле үзидарә органы җитәкчесе ____________________ ________________________ ____________

(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (дата)

М.У.

______________________________________________